# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында" Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 24 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында" 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә:

а) 4 пунктта "ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар," сүзләреннән соң "ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар," сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ һәм $4^2$ пунктлар өстәргә:

"$4^1$) ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы гаиләгә урнаштыруга бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр, баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләгән затлар;

$4^2$) уллыкка алынган балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр, уллыкка алучылар;";

2) 2 өлештә:

а) 2 пунтка "социаль наем шартнамәсе” сүзләреннән соң ", ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар яшәү өчен билгеләнгән махсус торак урыннарын яллау шартнамәсе," сүзләрен, "булган очракта)" сүзләреннән соң ", ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар яшәү өчен билгеләнгән махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәсен өзү һәм туктату, күрсәтелгән торак урыннарыннан чыгарылу" сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $10^1$ һәм $10^2$ пунктлар өстәргә:

"$10^1$) уллыкка алуны, ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга опека һәм попечительлек билгеләү, мондый балаларга опеканы һәм попечительлекне гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү;

$10^2$) ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау;";

3) 3 өлештә:

а) 1 пунктның "б" пунктчасына "социаль наем шартнамәсе” сүзләреннән соң ", ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, шул исәптән гаиләгә тәрбиягә алынган балалар, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар яшәү өчен билгеләнгән махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәсе" сүзләрен, "булган очракта)" сүзләреннән соң ", ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар яшәү өчен билгеләнгән махсуслаштырылган торак урыннарын яллау шартнамәсен өзү һәм туктату, күрсәтелгән торак урыннарыннан чыгарылу" сүзләрен өстәргә;

б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2) судларда түбәндәгеләр турында эшләр каралганда дәгъвачылар (мөрәҗәгать итүчеләр) булсалар:

а) алиментлар түләттерү;

б) туендыручысының хезмәт эшчәнлегенә бәйле рәвештә вафат булуы, имгәнүе яисә сәламәтлегенә башкача зарар килү аркасында китерелгән зыянны түләттерү;

в) уллыкка алуны, ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга опека һәм попечительлек билгеләү, мондый балаларга опеканы һәм попечительлекне гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү;

г) инвалид балаларга, ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар арасыннан һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга дәүләт ярдәме чараларын тәэмин итү;".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 11 ноябре
№ 88-ТРЗ